# Халкыбызның яраткан җырлары. 100 җыр

1 китап

Наследие нашего народа
**Любимые песни народа. 100 песен**
1 книга

ISBN 978-5-905160-05-9

**Халкыбызның яраткан җырлары. 100 җыр**
1 китап. Төзүчесе Рөстәм Сәрвәров

Казан, 2014. – 116 б.
© 2014 «Халкыбыз мирасы», «АКСУ» компаниясе

«Халкыбыз мирасы»

# Халкыбызның яраткан җырлары. 100 җыр

## 1 китап

Төзүчесе Рөстәм Сәрвәров

Казан 2014

# Баламишкин

*Татар халык җыры*

Машиналарга утырып
Кайтамын Казаннардан:
Яшь гомерне сатып алып
Булмый бит базарлардан.

Казан базарыннан алдым
Көмеш кашлы балдагым:
Бәлки рәхәт көннәр булыр,
Белеп булмый алдагын.

Казан урамнары ташлык,
Анда чәчмиләр ашлык:
Төрлебез төрле якларга
Таралдык та адаштык.

Китәм дисең, китәм дисең,
Казанга туктарсыңмы?
Бергә булган минутларны
Исеңдә тотарсыңмы?

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде, каласың.
Казан каласына хәтле
Әллә озата барамсың?

Идел борылышларыннан
Күренә Казан утлары,
Килә-килә килеп җитте
Аерылу минутлары.

# Олы юлның тузаны

*Татар халык җыры*

Олы юлның тузанын
Үзем күрдем тузганын.
Белми калдым, сизми калдым
Яшь гомеремнең узганын.

Олы юлның тузанында
Калды минем эзләрем;
Кайда икән яшьлегем, дип,
Шул юллардан эзләдем.

Олы юлның тузанында
Югалттым эзләремне.
Их, кайтарып алыр идем
Узган гомерләремне.

Олы юлдан атлар килә,
Безгә кала тузаны.
Алда гомер бардыр барын,
Сагындыра узганы.

# Зәңгәр төймә

*Татар халык җыры*

Иреннәрең кызыл чия,
Күзләрең зәңгәр төймә.
Гомерлеккә сөйдем сине,
Ташлап китәр бу, димә.

Зәңгәр төймәм, дип, иркәләп,
Назлап кына дәшәрмен.
Сүндермә мәхәббәтеңне,
Мин көч алып яшәрмен.

Гел сиңа гына багышлыйм
Җырларымның моңлысын.
Көтәм синнән, зәңгәр төймәм,
Мәхәббәтнең олысын.

# Кайтам инде

*Илдар Юзеев сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Ямансулап болыннарны буйлама,
Оныткандыр инде диеп уйлама;
Ничек итеп онытыйм мин ярымны?
Кара кашлы, назлы җанымны.

Ничек итеп онытыйм туган ягымны,
Анда узган алтын балачагымны;
Сагындырды Агыйделнең камышы,
Челтерәп аккан чишмә тавышы.

Сагындырды сызылып таңнар атуы,
Әнкәемнең иркәләп уятуы;
Кайтам инде, кайтам туган ягыма,
Кырларыма, тугайларыма...

# Беренче мәхәббәт

*Әхмәт Рәшитов сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Хәтердә ул тыныч айлы кичләр,
Хәтердә бормалы су юлы.
Онытылмый беренче саф мәхәббәт,
Онытылмый Агыйдел сылуы.

Ул мине утларда яндырды да,
Тилмертте аерылу газабы.
Нигә соң чәчәктәй яшь гомернең
Кавышу булмады азагы?

Юлларда киртәләр очратсагыз,
Күңелегез булса да яралы,
Сез искә алыгыз яшьли сөйгән,
Беренче яраткан ярларны.

# Мәдинәм-гөлкәем

*Татар халык җыры*

Кулъяулыгым икәү иде,
Берсе суларга акты;
Мәдинәм, гөлкәем,
Берсе суларга акты, бәгырькәем.

Икебезне ике якка
Тормыш дулкыны какты.
Мәдинәм, гөлкәем,
Тормыш дулкыны какты, бәгырькәем.

Мин сагынып хатлар язам,
Синең исеңдә дә юк.
Мәдинәм, гөлкәем,
Синең исеңдә дә юк, бәгырькәем.

# Җаным җәл түгел сиңа

*Татар халык җыры*

Алым җәл түгел сиңа,
Гөлем җәл түгел сиңа;
Алым түгел, гөлем түгел,
Җаным җәл түгел сиңа.

Алларым диям сине,
Гөлләрем диям сине;
Алым түгел, гөлем түгел,
Җаннарым диям сине.

Әрәмәдә карама,
Карамада кондыз бар;
Караңгы дип килми калма,
Ай булмаса, йолдыз бар.

# Җомга

*Татар халык җыры*

Тал бөресе, тал бөресе
Тал бөресе талларда;
Сандугачым, әйтеп сайра
Сөйгән ярым кайларда?

Сандугачым, очасыңмы,
Кипте инде күлләрең;
Синең янга барып кайта
Һәр көнне күңелләрем.

Акрын искән җил селкетә
Агыйдел камышларын;
Кем аерылмый, шулар белми
Аерылу сагышларын.

Агыйделләр дулкынлана,
Дулкынлана, комлана;
Басып сайрар талы сынса,
Сандугач та моңлана.

Моңлы кичтә тальян гармун
Кемнәр уйнатыр инде?
Син булмагач күңелемне
Кемнәр юатыр инде?

Гармуныңны тартып уйна
Үрләргә менгәндә дә,
Онытасым юк үлгәндә дә,
Гүрләргә кергәндә дә.

# Утыр әле яннарыма

*Шәүкәт Галиев сүзләре, Ифрат Хисамов музыкасы*

Оныт мәшәкатьләреңне,
Оныт инде беразга.
Сыйпап-сыйпап чәчләремне,
Бер иркәлә, бер назла.

Кушымта:
Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма.
Син утырсаң яннарыма
Ял була җаннарыма.

Йөзләреңә төбәп карап,
Килә бер сөенәсем,
Килә бер иркәләнәсем,
Килә бер сөяләсем.

Кушымта:

Күзләремә ашыгып кына
Салкын карап үтмә син.
Өстәп тор сөю ялкынын,
Гел өсти тор, бетмәсен.

Кушымта.

# Ай, җаный, суларда

*Татар халык җыры*

Әйдә, иркәм, алып барам
Чишмәләргә, суларга;
Чишмәләрдән су алганда
Су чәчрәтеп уйнарга.
Ай, җаный, суларда
Су чәчрәтеп уйнарга.

Өй эчләренә керәсең,
Гөлләргә үреләсең;
Гөлгә карыйм, сиңа карыйм –
Син матур күренәсең.
Ай, җаный, күз нурым,
Син матур күренәсең.

Атлар жиктем мин чанасыз,
Чыгып киттем чарасыз;
Күрер күзгә зур да түгел,
Чибәрлеккә чамасыз.
Ай, җаный, күз нурым,
Чибәрлеккә чамасыз.

Абау, бәгърем, керфегең,
Бирче миңа бөртеген;
Бик еракларга китәм ич,
Төсең итеп йөртермен.
Ай, җаный, керфегең,
Төсең итеп йөртермен.

# Яшьлегем тугае

*Фаил Шәфигуллин сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин музыкасы*

Ничәнче мәртәбә
Нурланып яз килде,
Тургайлар канатын кагынды.
Күзләрең сагышлы,
Дип әйтте бер тургай.
Нишлим соң, тургаем, сагындым.

Ничәнче мәртәбә
Тургайлар килделәр,
Тугайлар яшәрде, ямьләнде,
Өздереп сайрады,
Сайрады бер тургай
Читендер сагыну хәлләре.

Өздереп сайрама,
Хәлемне сорама,
Ул үзе аңлар бер, тургаем.
Минем күк сагынып
Кайтыр ул, тургаем.
Онытмас яшьлеге тугаен.

# Яшь гомер

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин музыкасы*

Яшь гомер бер узгач,
Кайтмый ул яңадан,
Тик минем яшьлек никтер кайтыр кебек;
Яшьлектә сөйгән яр,
Сагындым, килеп ал,
Сине көтәм һаман, дип әйтер кебек.

Юк, кайтмас яшь гомер,
Калды ул еракта,
Зәңгәр томан артында сагыш булып;
Яшьли сөйгән яр да
Ятка калды анда
Әллә язмыш, әллә бер ялгыш булып.

Ялгышны төзәтеп,
Язмышны үзгәртеп
Яшәсәң, яшьлек кире кайтыр кебек;
Яшьлек бит күңелдә
Иң матур җирендә.
Вакытлыча туктаган бер җыр кебек.

# Соңлама, кил инде

*Рәгыйдә Янбулатова сүзләре, Бәхти Гайсин музыкасы*

Ак чәчәк ата балан,
Күмелгәч гөлгә ялан.
Яшь йөрәк еш тибә
Искән җилләр миңа
Сөйгәнең килә, дисә.
Кушымта:
Кил, кил, кил,
Кил, иркәм, кил инде,
Кил, иркәм, кил инде,
Елмаеп көл инде
Сагындым, бәгърем, сине.

Алып кил син, дускаем,
Сандугач тавышкаен,
Мәхәббәтнең сафын,
Энҗеләргә хасын
Алып кил, аккошкаем.
Кушымта.

# Җаныем, бәгърем

*Татар халык җыры*

Иртә буран, кичтә буран,
Мамык шәлеңне уран, шул,
Мамык шәлеңне уран.
Кигән киемең күрсәм дә,
Җаныем, бәгърем,
Үзең күргәндәй булам.

Ишек алдында йөримен,
Карлар яуса, көримен, шул,
Карлар яуса көримен.
Синнән башка ямь табалмый,
Җаныем, бәгърем,
Ямансулап йөримен.

Тимер чана карлар яра,
Бу йөрәгем ник яна шул,
Бу йөрәгем ник яна?
Бу йөрәгем белеп яна,
Җаныем, бәгърем,
Сөйгәнем ятка кала.

# Казан кичләре

*Хәсән Туфан сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Кил әле, Иделнең җиләс җиле,
Юлларга чәчәкләр сип әле,
Ак булып, саф булып истә калсын
Казанның кадерле кичләре.

Туган ил чакырган зур юлларга
Китәрбез таңнарда без моннан.
Озатып калырсың безне, Казан,
Баласын очырган кош сыман.

Иделгә сузылган айлы юлдан
Тын гына, моң гына җыр ага.
Сагынырбыз, дуслар, бу кичләрне
Чәчләргә чал кергән чорда да.

Ал гөлләр сибегез безнең юлга,
Иделнең иртәнге җилләре.
Мәңгегә, гомергә истә калсын
Казанның кадерле кичләре.

# Наласа

*Татар халык җыры*

Өздереп гармун уйныйлар
Наласа авылында.
Йөрәгемә утлар яктың
Янам мин ялкыныңда.

Төнбоеклы тирән күлдә
Тезелеп йөзә аккошлар.
Үсеп җиткәч чит җирләрдә
Йөртә безне язмышлар.

Балачагым гөрләп үтте
Наласа кырларында.
Сагынуларым, сагышларым
Бу моңлы җырларымда.

Әй, Наласа-Наласа,
Наласаны су баса.
Арчаны да басар иде,
Тау башында тормаса.

# Чыгарсыңмы каршы алырга

*Дамир Гарифуллин сүзләре, Вәсим Әхмәтшин музыкасы*

Тыңларсыңмы яшьлек хисләремне,
Җырларымны кушып җырласам?
Каршы төшмәссеңме йөрәгеңне,
Мәхәббәтем белән чорнасам?

Минем белән тормыш сукмагыннан
Риза булырсыңмы үтәргә?
Аерылганда вәгъдә бирерсеңме
Кабат кайтуымны көтәргә?

Ашкынулы йөрәк көтә көн дә
Уртак таңның сызылып атканын,
Яшьлегемне җырга салган чакта
Кушылып җырларсыңмы, аппагым?

Кайткан чакта Сарман буйларына
Яннарыңа мәңге калырга,
Кырык эшең ташлап кырык якка
Чыгарсыңмы каршы алырга?

# Сагыну җыры

*Гыйльман Идрисов сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы*

Ак чәчәкләр кебек кар ява,
Хәтерләтеп ямьле май кичен,
Шомырт чәчәк аткан тугайда
Йөргән идек икәү нур кичеп.

Тормыш юлларыбыз шул кичтә
Аерылды төрле якларга,
Ә шулай да иркәм гел истә,
Алыштырмам аны ятларга.

Араларда озын юллар бар,
Үтәр идем дә бит арымый –
Очрашырга күпме еллар бар,
Ничек түзәрмен соң сагынмый?

# Сагыну

*Татар халык җыры*

Бездә биек таулар бар ла,
Тау астында таллар бар.
Талда яфрак, миндә сагыш,
Сездә нинди хәлләр бар?

Тау астында салкын чишмә,
Агып төшә улакка.
Сагынуымны әйтер идем,
Җил дә исми шул якка.

Алмалар өзәр идем лә,
Бауларга тезәр идем.
Янмаса бу йөрәккәем,
Сагынуга түзәр идем.

Салкын чишмә буйларында
Атлар эчерсәң иде.
Туган-үскән илләреңдә
Гомер кичерсәң иде.

# Ак кораб

*Татар халык җыры*

Агыйделдә ак кораб, ла,
Утырдым алга карап,
Бер генә сүз әйтер идем
Нурлы йөзеңә карап.

Агыйделне иңләп буйлап
Йөзәрсең үрдәккәем,
Бик күп кайгылар кичердең,
Түзәрсең, йөрәккәем.

Кайгы димә, хәсрәт димә,
Кайгыларга баш имә,
Кайгыларга башың исәң
Рәхәт яшәрмен димә.

Агыйделкәйне кичкәндә
Җырлыйм ишкәк ишкәндә,
Өзелә үзәк, яна йөрәк
Җаныем искә төшкәндә.

Агыйдел суы тирбәлә,
Уртасында сал булса.
Суга салсаң, калкып чыгар,
Безгә насыйп яр булса.

# Назлы гөлкәем

*Ярлы Кәрим сүзләре, Фасил Әхмәтов музыкасы*

Сөям, бел, сине,
Сөям гел сине.
Моң-зарларымнан
Көям шул инде.
Моң-зарларымнан
Көям шул инде,
Гөлкәем, бәгырем,
Нишлим соң инде?!

Иртә мин уйлыйм,
Кичтә мин уйлыйм.
Күрсәм үзеңне
Һич тә мин туймыйм.
Күрсәм үзеңне
Һич тә мин туймыйм.
Иркә баладай
Килче, кил, уйныйм!

Килче, кил, бәгырем!
Килче, серләшик.
Ал чәчәкләрдән
Илһам эзләшик.
Ал чәчәкләрдән
Илһам эзләшик.
Былбыллар кебек
Гөр-гөр гөрләшик.

# Замечательная

*Татар халык җыры*

Былбыл оча, былбыл оча,
Былбыл оча Болгарга.
Моңлы кешеләрне җәллим,
Үзем моңлы булганга.

Әй, кара күз, кара каш, замечательная,
Ошадың күңелләремә, ятларга бирү кайда.

Барган идем Самарага
Урамнарын санарга.
Безгә Ходай язган иде
Утлар булып янарга.

Әлкиләргә барган чакта
Кичтем Актай елгасын.
Җиде ярны ярың итсәң,
Мендәр тешләп еларсың.

Идел ага Сембергә
Агыйдел белән бергә.
Безнең болай утырулар
Калсын гомер-гомергә.

Казан диләр, Казан диләр,
Казанны күрсәң иде.
Шул Казанның уртасында
Подручком йөрсәң иде.

# Аерылабыз

*Татар халык җыры*

Аерылабыз, аерылабыз
Аерылабыз, мин китәм.
Вакытлача аерылганга
Түзәргә кирәк, иркәм.

Аерылабыз, аерылабыз
Аерылабыз күпкәме?
Әллә айга, әллә елга,
Әллә гомерлеккәме?

Аерылабыз, аерылабыз,
Бир, иркәм, кулларыңны.
Киләчәккә бәхетсезлек
Өзмәсен юлларыңны.

Агыйделдә өч үрдәк,
Өчесенә бер оя,
Аерылмабыз дигән идек,
Аера икән дөнья.

# Ашхабад

*Татар халык җыры*

Әй, дусларым, дусларым, ла,
Дусларым, дус-ишләрем.
Сез дуслардан аерылсам
Ялгыз башым нишләрмен.

Әй, дусларым сезнең белән
Шат минем күңелләрем,
Тагы да шулай шатлык белән
Үтсә иде гомерләрем.

Уйсу җирдә су була,
Су аслары ком була.
Яшь вакытта уйна да көл,
Картайгачтын соң була.

Әй, дусларым, дусларым, ла,
Дусларым, бәгырләрем,
Яшь гомерләр ике килми,
Белегез кадерләрен.

# Ай былбылым

*Татар халык җыры*

Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделнең камышы,
Таң алдыннан чут-чут килә
Сандугачлар тавышы.

Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделдә таң ата,
Таңнар ата, өзелә үзәк,
Җырлата да елата.

Ай былбылым, вай былбылым,
Кунып сайрый талларга,
Синең хакта серләремне
Сөйлим сандугачларга.

# Күбәләгем

*Татар халык җыры*

Күбәләк гөлләргә кунса,
Гөлләр тибрәнә микән?
Ул да мине сагынганда,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Җырлап җибәрә микән?

Күбәләккәй гөлгә кунган,
Гөлдә булгач оясы,
Минем күңелем сиңа тарта,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Син бит күңелем кояшы.

Тау астында, тал астында
Салкын чишмә түгәрәк,
Очып барып кайтыр идем,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Әгәр булсам күбәләк.

Күбәләкләр бик күп алар,
Оча белгәне сирәк,
Үзеңә тиң күбәләкне
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Сайлый белергә кирәк.

# Алмагачлары

*Татар халык җыры*

Алмагачы чәчәк ата
Майның унбишләрендә.
Алмагач чәчәге кебек
Керәсең төшләремә.

Эх, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары.
Җырлый-җырлый,
Сайрый-сайрый,
Яши сандугачларым.

Алма бөреле, алма бөреле,
Алма чәчәге төрле.
Башкаларга күз дә салмыйм
Сине күргәннән бирле.

Эх, алмагачлары,
Йомшак икән куллары.
Йомшак булса да куллары,
Үземә насыйп булмады.

Алма бакчасына керсәм,
Бадьян түтәлләре.
Ал булса да, гөл булса да,
Кирәкми бүтәннәре.

Алмагачым алма бирми,
Калды инде чыбык кына.
Булдым инде сайрар коштай,
Сайрамыйм чыгып кына.

Алмагачның агачыннан
Кашык юндым мин сиңа.
Уналтыда, унҗидедә
Гашыйк булдым мин сиңа.

Алма бакчасында үзем,
Гөл бакчасында күзем.
Язып түгел, сөйләшеп тә
Бетәрлек түгел сүзем.

Алмагачның алмасын
Ал булмый ашамыйлар.
Яратмагач, башламыйлар
Башлагач, ташламыйлар!

Алмагачның алмасын
Асыл кошлар ашасын.
Мине ташлап, ятны сөйсәң
Ул дә миңа охшасын.

Алмагачым бар чагында
Таянмаем талларга.
Сез дусларым бар чагында,
Ялынмаем ятларга.

Алмагачын вак диләр,
Чәчәкләрен ак диләр!
Кая барсаң, кайда йөрсәң,
Сез дусларны мактыйлар.

# Очрашу җыры

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Илһам Шакиров музыкасы*

Килдем, дуслар, Идел – диңгез кичеп,
Сезне сагынып, кошлар кебек очып.
Кош канатлары түгел иңемдә,
Җыр канатлары минем күңелемдә.

Кушымта:
Җырлыйк, дуслар, җырлыйк бергәләшеп,
Иң матур җырларны сайлап кына,
Иң матур җырларны сайлап кына,
Яшик бу илләрдә сайрап кына.

Бүләк итеп чәчәкләр өзмәдем,
Сезгә мин иң матур җыр эзләдем.
Матур җыр таптым туган илемнән,
Моңлы көй оттым тургай теленнән.

Кушымта.

# Сәяхәтче җыры

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин музыкасы*

Таныш түгел юллар буйлап
Мин озак йөрдем.
Туган ягым күренерме дип,
Тауларга мендем.
И гүзәл туган ягым,
И ямьле туган ягым,
Тау башында бакча булып,
Төшемә кердең.

Туган яктан ерак китеп,
Диңгезләр кичтем.
Сагыш дигән тирән күлнең
Суларын эчтем.
И гүзәл туган ягым,
И ямьле туган ягым,
Тальян гармун моңы булып,
Җырыма күчтең.

Туган яктан еракта да
Дуслар очраттым.
Ләкин яшьлек дустым калган
Илемә кайттым.
И гүзәл туган ягым,
И ямьле туган ягым,
Бәхетемне читтә түгел,
Мин синдә таптым.

# Сагыш

*Равил Фәйзуллин сүзләре, Җәүдәт Фәйзи музыкасы*

Мин сиңа йомшак таң җиле
Юллаган идем,
Чәчләреңнән иркәләр дип
Уйлаган идем.

Мин сине сагынып бер җыр
Чыгарган идем.
Җан дуслар яратып аны
Тыңлаган иде.

Җыр сиңа ошар дип йөрдем,
Ваемсыз булып.
...Ә ул сиңа барып җиткән
Авыр сүз булып.

Хәзер җилләр дә юлламыйм,
Чыгармыйм җыр да.
Теләсәң, үзең җанымны
Кил дә бер тыңла.

# Мәк чәчәге

*Альберт Абдуллин сүзләре, Марс Макаров музыкасы*

Мәк чәчәге өздем ялгыш кына,
Чүп үләне белән бутадым.
Мәк чәчәген, белми киләчәген,
Үз кулларым белән утадым.

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына,
Күз яшьләре түктең син шуңа.
Чәчәкләргә багышланган гомерең
Туктаган күк булды юлында.

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына,
Шиңгән чәчәк яшәрмәс инде;
Вакыт үтәр, күз яшең дә кибәр,
Бәлки, гафу итәрсең мине.

# Әйткән идең

*Хәсән Туфан сүзләре, Әнвәр Бакиров музыкасы*

Әйткән идең «Әгәр сөя калсаң
Миннән башка берәр бүтәнне,
Сөй… бары тик миннән яхшыракны,
Сөймә ләкин миннән түбәнне…»

Юлыктым мин, Лулу, бер чәчәккә,
Көтмәгәндә, уйламаганда.
Нәкъ синдәйгә, синең шикеллегә,
Әйтерсең лә синең дәвамга…

Тормышымның синнән соңгысында
Тапканым юк иде һичкемне.
Нишләргә соң? Бир бер киңәш миңа:
Ул һәр яктан синең шикелле.

«Нишләргә соң?» – дигән сорау белән
Киләм синең рәсемең каршына…
Үзең булсаң әгәр, мондый уйлар
Килер идемени башыма?

# Ядкарь

*Разил Вәлиев сүзләре, Фасил Әхмәтов музыкасы*

Күптән инде, күптән очрашкан юк,
Хәтерлимсез бергә чакларны?
Күңелләрдә йөргән татлы сагыш –
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Уртак иде хисләр, айлы кичләр, –
Без кертмәдек анда ятларны.
Күңелләрдә йөргән дуслык хисе –
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Бергә откан өмет тулы җырны
Йөрәк инде мең кат ятлады,
Үткәннәрдән бары шул җыр калды, –
Ул җыр безгә яшьлек ядкаре.

# Оныттың бугай

*Гәрәй Рәхим сүзләре, Гали Ильясов музыкасы*

Сине уйласам, мине моң баса,
Борчылып йөрим инде ничә ай.
Күңелем сизә, назлы язларны
Оныттың бугай, оныттың бугай.

Еракта калды, дәртләнеп, ярсып,
Без җырлап үткән ул яшел тугай.
Кабатлап булмый торган чакларны
Оныттың бугай, оныттың бугай.

«Сөй!» – дип үтенмим, ләкин үкенмим
Яшьлектә сине сөйгәнгә шулай.
Син мине түгел, яшьлекнең үзен
Оныттың бугай, оныттың бугай.

# Сарман

*Татар халык җыры*

Сандугачлар кунып кайда сайрый?
Сарман буйларында, тирәктә шул,
Сарман буйларында, тирәктә.
Сиңа булган яшьлек мәхәббәтем,
Үрелеп чәчәк ата йөрәктә.

Сарман буйларында үткән чакта,
Тыңларсыңмы җырлар, җырлармын шул,
Тыңларсыңмы җырлар, җырлармын.
Күзләреңне тутырып карасаңмы,
Зәңгәр таудан яулык болгармын.

Сарман буйларында яшел алан,
Печәннәре җитәр бер заман шул,
Печәннәре җитәр бер заман.
Каушулары иркәм бик күңелле,
Әммә аерылышу бик яман.

# Мәтрүшкәләр

*Илдар Юзеев сүзләре, Алмаз Гыйлаҗев музыкасы*

Мәтрүшкәләр, кипкән мәтрүшкәләр,
Ераклардан әнкәм җибәргән.
Мәтрүшкәләр, кипкән мәтрүшкәләр
Туган кырларымда тибрәлгән.

Тирән сагынудан уйчанланган
Күз карашын сезгә төбәлгән:
Әйтегезче миңа, мәтрүшкәләр,
Ни әйтергә әнкәм теләгән?

Мәтрүшкәләр мине уяттылар,
Сискәндереп гамьсез төннәрдә.
«Мәтрүшкәләр кебек кибәрсез сез,
Аерылсагыз туган җирләрдән…»

# Сине уйлап янам

*Илдар Юзеев сүзләре, Сафьян Ибраһимов музыкасы*

Җәйләүләрдә тугай,
Тугайларда тургай
Җилләргә лә каршы баралмый,
Сине уйлап янам,
Ник килмисең һаман,
Күңелем эзли сине, табалмый.

Карурманга таба
Чишмә чыңлап ага,
Җил көчәйтте аның агышын,
Мин утырам тыңлап,
Шул сулардай чыңлап,
Агып китәр микән сагышым?

Җәйләүләрдә тугай,
Тугайларда тургай –
Канатларын җилпи җилләрдә,
Сине уйлап янам,
Ник килмисең һаман,
Күңелләрең синең кемнәрдә?

# Җидегән чишмә

*Гомәр Бәширов сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Җидегән чишмәләрдә җиде улак,
Челтер-челтер ага көмеш су.
Көмеш сулар ага, кошлар сайрый,
Шул чакларда бигрәк ямансу.

Җидегән чишмәләргә йөзек салдым,
Җидегән йолдыз күреп калсын, дип.
Җанкай-җанаш алсын да куансын,
Вәгъдәләрем булып калсын, дип.

Җидегән чишмәләргә чиләк куйдым,
Пар чиләгем тизрәк тулсынга.
Без сөябез, җаный, яр булсынга,
Без йөрмибез вакыт узсынга.

Җидегән чишмәләрнең талы бөгелә,
Акрын искән җәйге җилләрдә.
Сез каласыз инде, без китәбез,
Без китәбез ерак илләргә.

# Җиз кыңгырау моңнары

*Әнгам Атнабаев сүзләре, Вәсил Хәбисламов музыкасы*

Урап-урап карлар күмә
Кышның озын юлларын,
Чың-чың итеп, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын.
Җиз кыңгырау, көмеш моңнар
Уйлата синең хакта,
Синең хактагы уйларым
Яшьлеккә алып кайта,
Уйлата синең хакта.

Чың-чың итә, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын.
Кая алып бара икән
Кышкы озын юлларым?
Җиз кыңгырау моңнарында
Үткәннең тавышлары,
Очрашулар, кавышулар,
Аерылу сагышлары,
Үткәннең тавышлары.

Урап-урап карлар күмә
Кышның озын юлларын,
Чың-чың итә, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын.
Җиз кыңгырау табып кына,
Атларда чабып кына,
Килер идем яшьлегемнән
Тик сине алып кына,
Атларда чабып кына.

# Ак чәчәкләр

*Әкрам Даутов сүзләре һәм музыкасы*

Таллыкта алан,
Аланны япкан
Ап–ак чәчкәләр.
Без бергә идек,
Калфаклар үрдек
Шул ак чәчкәдән.

Алсу йөзеңә
Бигрәк килешә
Чәчкә калфагың!
Синнән дә сылу
Чәчкәләр булу
Мөмкинме тагын!

Дөрләсен хисләр!
Тәмле, хуш исләр
Җилдә уйнасын!
Безнең күңелләр
Сулган чәчкәләр
Кебек булмасын.

# Алтын алка

*Татар халык җыры*

Алтын алкаларым сынса,
Көмешен сындырмамын.
Үлсәм дә, сөйгән ярымны
Ятларга калдырмамын.

Өйләремә элеп куйдым
Асмалы паласымны.
Үзем сөйдем, белеп сөйдем
Ятларга каласыңны.

Алтын алкаларым сынды,
Алырсың микән алка?
Булырсың микән үземә,
Калырсың микән ятка?

Яңа яуган кар өстеннән
Атлый бәхетле парлар.
Нигә соң бергә булалмый
Бер-берсен сөйгән ярлар?

# Юллар

*Әхмәт Ерикәй сүзләре, Ләбиб Айтуганов музыкасы*

Бизмәгәндәй яшәү бәхетеннән,
Юл йөрүдән мәңге бизмәм мин:
Юллар, юллар, инде ничә еллар
Аерыла алмыйм сездән мин.

Алларымда якты йолдыз төсле
Мавыктыргыч утлар яналар:
Юллар, юллар, борма-борма юллар
Шул утларга таба баралар.

Яшьлек хисен, тынгысызлык дәртен
Вакыт яңгырлары юмасын.
Юллар, юллар, авыр булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын.

Тирбәндереп якты уйларымны,
Җәйрәп ята данлы, киң илем:
Юллар, юллар, алга таба дәшә,
Бармый калыр хәлем юк минем.

# Саубуллашу вальсы

*Саҗидә Сөләйманова сүзләре, Мәсгут Имашев музыкасы*

Ак алъяпкычларда ак канат,
Күңел оча, гүя, акчарлак.
Ак канат иңнәрдә,
Җилферди җилләрдә,
Күңел оча ерак җирләргә.

Аерылыр чак җитә, дусларым,
Сизелмәде ун ел узганы.
Хуш, мәктәп, үз күрдең,
Яшәргә көч бирдең,
Канат куеп безне үстердең.

Алда юллар – кайсын сайларга,
Юллар чакыра әллә кайларга, –
Океаннар айкарга,
Очарга айларга,
Тормыш дәрьясында кайнарга.

Альяпкычың, дустым, ак икән,
Ак булса да салыр чак җиткән.
Хыяллар – ак җилкән,
Кузгалырбыз иртән,
Ерак юлга чыгар чак җиткән.

# Белегез шуны

*Илгизәр Фазлуллин сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Иртә таңнарда карыйм талларга,
Өзә үзәкне кошларның моңы.
Аерылсам сездән, якын дусларым,
Саргаер идем, белегез шуны.

Көзләр җитүен, кошлар китүен,
Күпме кичерде гомерләр юлы!
Кояшлы язым, чәчәкле җәем
Сез ул, дусларым, – белегез шуны.

Нурлана күзләр, тәмләнә сүзләр,
Бетә таралып күңелнең моңы.
Күрсәм яңадан сезне, дусларым,
Бәхетем арта, белегез шуны.

# Туган авылым

*Нәҗип Иделбай сүзләре, Тәлгать Шәрипов музыкасы*

Туган авылым минем,
Куенында синең
Гөрләп үтте үсмер елларым.
Кырларың хуш исле,
Һәрчак язлар төсле,
Шунда туды тәүге җырларым.

Инеш буең ямьле,
Суларың да тәмле,
Җилләрең дә назлы, ягымлы,
Айлы кичләрең дә
Әле исләремдә, –
Яратам мин туган ягымны.

Яланнарың иркен,
Авылымның күрке –
Сызылып аткан алсу таңнарың.
Һаман синдә күңел,
Онытырлык түгел,
Сайрар кошларыңның моңнарын.

# Әйдә, әйдә, кая, кая

*Керәшен халык җыры*

Әйдә, әйдә, кая, кая,
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага.
Авылыбызда бер чибәр бар
Әйдә салыйк шобага.

Телеграф баганасы
Олы юлга маяк ул.
Сагынасызмы дип сорыйсыз
Сагынмаган кая ул.
Сагынасызмы дип сорыйсыз
Сагынмаган кая ул.

Әйдә, әйдә, кая, кая,
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага.
Авылыбызда бер чибәр бар
Әйдә салыйк шобага.

# Зимфирәкәй

*Абдулла Мостафин сүзләре, Васил Хәбисламов музыкасы*

Зимфирәкәй, кемгә гөлләр өздең,
Арышларда йөрегән чагында?
Сандугачтай матур, сылу кебек
Күбәләкләр оча юлында.

Зимфирәкәй, сылу, аппагым,
Кош канаты, кыйгач кашларың.

Зимфирәкәй алтын йолдыз кебек
Авылымның балкый күгендә.
Сандугачтай көтәм сине өзелеп,
Мәхәббәтем үсә күңелемдә.

Зимфирәкәй, сылу, аппагым,
Җырларымны сиңа сакладым.

Зимфирәкәй, синдә минем уйлар,
Хыялым да минем, өметем.
Сандугачтай үтсен безнең еллар
Тояр өчен йөрәк җылысын.

Зимфирәкәй, сылу, аппагым,
Җырларымны сиңа сакладым.

# Гөлнарым

*Гамил Афзал сүзләре, Фәрит Хатыйпов музыкасы*

Сандугачтай сайрап уйнадың да
Кына гөлләренә кунмадың.
Гөлнарым,
Үкенечкә ярым булмадың.

Яулыгыңны болгап җырладың да
Йөрәкләрне телде моңнарың.
Гөлнарым,
Борылмалы киткән юлларың.

Сине сагынып уйлар уйладым да
Чишмә буйларыннан урадым.
Гөлнарым,
Күз алдымда зифа буйларың.

# Рәзинәкәй

*Салават Сәрвәров сүзләре һәм музыкасы*

Рәзинәкәй, алсу йөзләреңне
Төшләремдә күреп уянам.
Синең кара күзләреңне,
Сөям дигән назлы сүзләреңне,
Ал яулыгың күреп моңланам.

Син еракта хәзер, йөрәгеңдә
Башка гөлләр чәчәк аткандыр.
Синең керсез сөюләрең,
Мәхәббәттә янып-көюләрең
Күз яшьләре булып тамадыр.

Саргаямын, ахры, сине уйлап,
Күз карашың карап туймыйча.
Йөрәгемдә булган кара тапка,
Эзсез калган керсез мәхәббәткә
Гафу үтенергә кыймыйча.

# Әкълимә

*Рим Хәсәнов сүзләре һәм музыкасы*

Син минем ягыма карамыйсың да,
Син минем турыда уйламыйсың да.
Карама, уйлама, эндәшмә, Әкълимә, –
Барыбер син бит уемда!

Йөрәгем җылынып китә,
Елмаеп карасаң үземә.
Карама, уйлама, эндәшмә, Әкълимә,
Син генә минем уемда!

Барыбер кар эрер, су булып китәр,
Яз көне йөрәкнең кылларын чиртер.
Мин көтәм сагынып, кил минем яныма,
Гүзәлем минем, Әкълимә!

Йөрәгем җылынып китә,
Елмаеп карасаң үземә.
Карама, уйлама, эндәшмә, Әкълимә,
Син генә минем уемда!

# Өнсә авылы көе

*Татар халык җыры*

Безнең авыл өсләрендә
Йолдыз яна яктырак ла:
Айга да йолдыз бик якын,
Син генә миннән ерак.

Исмә (ә)ле, җил, тукта (ә)ле, җил,
Өзмә гөлләр чәчәген шул:
Алга килми белеп булмый
Башның ни күрәчәген.

Кыйблалардан искән җилдән
Бөгелә талның нечкәсе лә:
Йөрәгемнең саф җиреннән
Чыга сагыш чишмәсе.

Сызылып таңнар аткан чакта
Ямансу була язын ла:
Аерыласын алдан белдем, –
Ялгыз күрдем кыр казын.

# Күн авылы көе

*Татар халык җыры*

Биек тауларның башында
Утырып уйлар уйладым да:
Утырып уйлар уйлар өчен,
Үскән икән буйларым.

Тальян гармун телләрендә
Уйный биш бармак кына:
Агач яфраклары кебек,
Саргаям салмак кына.

Гармун бәләкәй булса да,
Әйтә ул кирәкләрен:
Сикереп суларга төшәрсең,
Янса яшь йөрәкләрең.

Сандугачым, сайрап җибәр,
Талларың тамырлана:
Салкын сулар эчеп кенә
Йөрәгем сабырлана.

Басу капкасын чыккач та,
Күтәрелде томаннар:
Дөнья хәлен белеп булмый,
Сау булыгыз, туганнар.

# Туган авылыма

*Мостафа Ногман сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Чынлы суы җәелеп ага,
Язгы ташкыннар килсә:
Ташкыннар кебек шаулашып,
Авылымда яшьләр үсә.

Кушымта:
Туган авылым минем каршымда,
Күңелем һаман омтыла шунда.

Еraклардан карап киләм
Чынлы басуларына.
Шунда гына тынгы табам
Күңелем ярсуларына.

Кушымта:
Шушы кырлар буйлап минем
Яшьлек юлларым үткән.
Шул юллардан яшьлек дустым
Елмаеп чыкса икән!

# Моңнар кайтсын авылга

*Рамил Чурагулов сүзләре, Ризван Хәкимов музыкасы*

Авыл киче. Тасмалардан
Әй, агыла ят моңнар.
Нинди моңсу, әллә инде
Телсез калган гармуннар?

Кушымта:
Әйт, авылым, кайда соң моң?
Моң кайда соң, әйт, урам!
Аулак өйле һәм гармунлы
Яшьлегемне сагынам.

Авыл киче ник соң моңсу,
Күңелем ник буш шулай?
Өй түрендә тальян гармун
Моң сагынып зар елый.

Кушымта:
Йөрәкләргә очкын салып
Гармунымда уйныймын.
Авылыма моңнар биреп
Урамнарны буйлыймын.

Авыл киче. Яшь йөрәкләр,
Гармун моңга сусаган.
Сөю булып моңнар кайтсын
Авылыма яңадан!

# Әйтмә син авыр сүз

*Рамил Чурагулов сүзләре, Ризван Хәкимов музыкасы*

Беркайчан әйтмә син авыр сүз
Бик кыска, әй, кыска гомерләр.
Син минем гомерлек юлдашым,
Син чәчкәм, йолдызым, сөйгән яр.

Әйтмә син авыр сүз, әйтмә син,
Йөрәк бит болай да яралы.
Җырларны шаулатып җырлыйсы,
Гөрләтеп яшисе бар әле.

Бик авыр минутлар булса да,
Тап миңа шул вакыт җылы сүз;
Авыр сүз әйтәсең килсә дә
Әйтмә син, сөеклем, әйтмә, түз.

Әйтмә син авыр сүз, әйтмә син,
Йөрәк бит болай да яралы.
Җырларны шаулатып җырлыйсы,
Гөрләтеп яшисе бар әле.

Иртәсен, кичен дә миңа син
Кызганма карашың җылысын.
Шул чакта сөюем артуын
Йөрәгең белән син тоярсың.

Әйтмә син авыр сүз, әйтмә син,
Йөрәк бит болай да яралы.
Җырларны шаулатып җырлыйсы,
Гөрләтеп яшисе бар әле.

# Бәрәңге

*Мәхмүт Хөсәен сүзләре, Ифрат Хисамов музыкасы*

Вак-вак итеп турап, яшь киленнәр
Табаларда сине биетә:
Кайнар боткаң ашап, эшчән ирләр
Тәннәренә җылы йөгертә.

Йодрык кадәрле,
Йомры гәүдәле,
Ак тәнле, эх,
Бигрәк тәмле бәрәңге!

Күлмәгеңне салып, моңсуланып,
Кайнар шулпаларга төшәсең.
Ялкын кызуында алсуланып,
Учак көлләрендә пешәсең.

Йодрык кадәрле,
Йомры гәүдәле,
Ак тәнле, эх,
Бигрәк тәмле бәрәңге!

Тукай да бит сине җырга керткән,
Бабайларда мактап сөйләгән:
Бер як та юк сине яратмаган,
Беркем дә юк сине сөймәгән.

Йодрык кадәрле,
Йомры гәүдәле,
Ак тәнле, эх,
Бигрәк тәмле бәрәңге!

# Бөрлегәнем бергенәм

*Татар халы җыры*

Бакчаларда чәчәк ата.
Син утырткан бөрлегән.
Ул да сине көтә сыман,
Ник килмисең, бергенәм?
Бөрлегәнем бөрлегән,
Сагындырдың, бергенәм.

Бүген төнлә төшләремдә
Сине күрдем, бергенәм
Син тал, имеш, ә мин, җаным,
Гүя кара бөрлегән,
Бөрлегәнем, бөрлегән,
Бик сагындым, бергенәм.

Бөрлегәндәй күзләреңне
Бик сагындым, бергенәм.
Сөям дигән сүзләреңне
Кабатлыймын җыр белән.
Бөрлегәнем, бөрлегән,
Син бит минем бергенәм.

# Кошлар кебек

*Татар халык җыры*

Һаваларда очкан кошлар кебек,
Ярсый-ярсый канат кагынып,
Туган илем, кайттым мин талпынып,
Күз нурларым, сезне сагынып.

Һаваларда очкан аккошларның
Канатлары җилдә каерылмый.
Яшәр идем, туган илем, синдә,
Якын дусларымнан аерылмый.

Һаваларда очкан аккошлардан
Коела җиргә мамык тузаны.
Туган илдә сөйгән дуслар белән
Сизелми лә гомер узганы.

Һаваларда очкан аккошларның
Каурыйлары коела җилләрдә.
Туфрагына алтын чәчсәләр дә,
Җитми икән туган илләргә.

# Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?

*Нәсимә Абзалова сүзләре, Илһам Хисмәтуллин музыкасы*

Чәчкәләрнең нигә кирәге бар,
Бүләк итәр кешең булмагач,
Нәрсә соң ул күктә янган кояш
Үз кояшың балкып тормаса?

Син янымда булган чакта гына
Матур җырлар туа күңелемдә.
Эчкерсез саф мәхәббәтем минем
Юлдаш булсаң иде гомергә.

Тормыш юлын бергә башлаганбыз,
Ахыргача бергә булыйк без.
Авырлыклар килсә, бергә уртаклашыйк
Шатлыкларны бергә бүлик без.
Бик бәхетле, иркәм, булыйк без.
Тормыш юлын бергә үтик без.

# Аерылмагыз

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Чулпан Зиннәтулина музыкасы*

Су буенда ялгыз аккош,
Каерылган канатлары.
Канатларны каера ул
Аерылу газаплары.

Кушымта:
Аерылмагыз, аерылмагыз,
Булса да сәбәпләре.
Канатларны каера ул
Аерылу сәгатьләре.

Ят кошны пар итмәс аккош
Ялгыз канат какса да.
Без дә бергә булалмабыз
Сулар үргә акса да.

Кушымта:
Ялгыз аккош күргән саен
Өзелә бәгырьләрем.
Нигә без бергә чакларның
Белмибез кадерләрен?!

Су буенда ялгыз аккош,
Каерылган канатлары.
Канатларны каера ул
Аерылу газаплары.

Кушымта:
Аерылмагыз, аерылмагыз,
Булса да сәбәпләре.
Гомерләрне кыскарта ул,
Аерылу сәгатьләре.

# Сиңа килдем, иркәм

*Гыйльман Идрисов сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы*

Сиңа килдем, иркәм,
Үткән юлларымның
Саный-саный ерак чакрымнарын.
Килдем, тормышымда кичеп язмышымның
Шатлыкларын, көчле ялкыннарын.

Сиңа килдем, иркәм,
Килдем еллар буе,
Саный-саный үткән көннәремне,
Баса алмаенча ярсып януларын
Әрнеп өзгәләнгән йөрәгемнең.

Сиңа килдем, иркәм,
Бик сагынып килдем,
Шаулап-гөрләп ямьле язлар җиткәч,
Ераклардан язган сәлам хатларыңны
Көтә-көтә түземлегем беткәч.

# Чәчәкләр уяныр

*Ринат Мөслимов сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы*

Яз көннәренә олы ямь өстәп,
Аккошлар кайтты син киткән яктан.
Сәламнәреңне алар әйтмиләр
Миңа еректан, миңа еректан.

Сиңа дип атап чәчәкләр җыйдым,
Җыйган чәчәкләр шиңделәр инде.
Кайтыр әле, дип көткән өметләр
Сүнделәр инде, сүнделәр инде.

Шиңгән чәчәкләр кабат терелер
Кайту хәбәре синнән килгәч тә.
Сүнгән өметләр кабыныр яңадан
Сине күргәч тә, сине күргәч тә.

# Уфа юкәләре

*Наҗар Нәҗми сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы*

Яшьлек урамнары,
Тулы хыяллары,
Без – шатлыкка туймас исәрләр.
Уфа юкәләре
Безнең хакта да әле
Яфрак яра-яра сөйләрләр.

Безнең менгән атлар,
Еллар, аргамаклар,
Көмеш тезген, алтын йөгәннәр.
Уфа юкәләре
Безнең хакта да әле
Чәчәк ата-ата сөйләрләр.

Гомер ике килми,
Утлар ике сүнми,
Без – мең янып тик бер сүнәрләр.
Уфа юкәләре
Онытмаслар әле,
Яфрак коя-коя сөйләрләр.

# Телефоннар

*Рим Хәсәнов сүзләре һәм музыкасы*

Телефоннар шалтырыйлар, хәбәр итәләр,
Алар бездән еракларга сәлам илтәләр.

Кушымта:
Әйтче, иркәм, әйт үземә,
Сөясеңме син?
Синең күзләреңә карап,
Гашыйк булдым мин.

Телефоннар шалтырыйлар, хәбәр итәләр,
Синнән миңа, миннән сиңа сәлам йөртәләр.

Кушымта.

Телефоннар, телефоннар һаман шалтырый.
Йөрәк яна, син һаман юк, күңел һич тынмый.

Кушымта.

# Юкка түгел, юкка түгелдер

*Нажар Нәҗми сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы*

Кая барма – җирдә матурлыклар,
Без – шул Җирдә туып үскәннәр.
Безгә кадәр, безгә кадәр дә бит
Җиргә күпме килеп киткәннәр.

Һәркемгә дә бирелмәгәндер ул
Яшәү-күкрәүләргә тиң гомер.
Бу дөньяга без килгәнбез икән,
Юкка түгел, юкка түгелдер!

Бер үк кояш һаман караса да,
Бер үк булмый заман җилләре.
Йолдыз белән йолдыз арасында
Балкып ята кеше эзләре.

Һәркемгә дә бирелмәгәндер ул
Яшәү-күкрәүләргә тиң гомер.
Бу дөньяда без яшибез икән,
Юкка түгел, юкка түгелдер!

Безнең өчен җирдә гөлләр үсә,
Карлар ява, җилләр исәләр.
Син ышанма, үзе өчен генә
Мине әгәр яши, дисәләр.

Бер күз ачып йомган ара гына
Безнең бергә үткән бу гомер.
Бер-беребезгә без кирәкбез икән,
Юкка түгел, юкка түгелдер!

# Кыңгыраулы мәктәп еллары

*Шәүкәт Галиев сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы*

Кошлар да бер шулай таралалар,
Сау бул инде, туган оябыз!
Офыкларга карап очар өчен
Иңнәрдә без канат тоябыз.

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Күңелләрдә гомерлеккә калыр
Шушы соңгы моңлы чыңлавы.
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

Зур юлларга безне чыгардың син,
Күңелләргә бирдең омтылыш.
Соңгы звонок булсын беренчесе,
Син каршыла безне, зур тормыш.

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Онытылмас, кая юл тотсак та,
Сагындырыр таныш чыңлавы.
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

Алда әле заман имтиханы,
Күп сынаулар әле үтәсе;
Максатларга әле ирешәсе,
Хыялларны чынлык итәсе!

Әйтерсең лә пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Киләчәккә безне озатканда
Онытылмас дәртле чыңлавы.
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

# Дусларыңны онытма

*Рим Хәсәнов музыкасы, Әнгам Атнабаев сүзләре*
*«Яшьлек белән хушлашу» спектакленнән*

Кош баласы канат белән туа,
Һаваларга менеп югала.
Кешеләр дә кош баласы кебек
Үз язмышын эзләп юл ала.
Тормыш юллары катлаулы –
Берьялгызың юл үтмә,
Йөрәк канаты булырдай
Дусларыңны онытма.

Орлыклардан гөлләр тусын өчен
Чәчкәләргә чәчкә эндәшә.
Кешеләр дә гөлчәчкәләр кебек,
Кешеләргә бәхет өләшә.
Тормыш юллары катлаулы –
Берьялгызың юл үтмә,
Йөрәк чәчкәсе булырдай
Дусларыңны онытма.

Төрле якка китәр юлларыбыз,
Онытмаек яшьлек юлларын,
Ерак еллар аша хәтерләек
Шушы саубуллашу җырларын,
Тормыш юллары катлаулы –
Берьялгызың юл үтмә,
Йөрәк җырлары булырдай
Дусларыңны онытма.

# Яран гөл

*Резеда Вәлиева сүзләре, Сәүбән Чуганаев музыкасы*

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана
Бәгырькәем мине күрде исә.

Кайгы-хәсрәтем дә юк сыман,
Йөрәккәем яна ут сыман.
Газапланам иртә-кичләрен,
Әйтә алмыйча йөрәк хисләрем.

Яннарыма гына килсә иде,
Сөям сине, бәгърем, дисә иде.
Күзләреннән алмый күзләрем
Сөйләр идем йөрәк серләрем.

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана
Бәгырькәем мине күрде исә.

# Туган авылым урамы

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Ганс Сәйфуллин музыкасы*

Туган җирем, үскән җирем –
Гади генә бер авыл.
Гади булса да, яз җиткәч,
Гөл бакчасы була ул.
Туган авылым урамын
Кабат-кабат урадым.
Баш очымда кош сайрады –
Бәхетемә юрадым.

Йортлары яңа булса да,
Минем авылым борынгы.
Онытма, туган авылым,
Яуда калган улыңны.
Туган авылым урамын
Кабат-кабат урадым.
Баш очымда кош сайрады –
Бәхетемә юрадым.

Авылымның топольләрен,
Белмим, кемнәр утырткан.
Туган телем, моңлы телем
Ишетелә һәр йорттан.
Туган авылым урамын
Кабат-кабат урадым.
Баш очымда кош сайрады –
Бәхетемә юрадым.

# Буразналар

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Җәүдәт Фәйзи музыкасы*

Китсәм, кайтам кырларыма
Янып көярлек булып.
Гармун сыры – буразнаны
Сыйпап сөярлек булып.

Буразналар, буразналар –
Йөгерек дулкыннар.
Буразнамда игенкәйләр
Күкрәп уңсыннар!..

Хезмәт шавы, кошлар җыры
Уятсын иген кырын.
Сызсыннар көмеш сабаннар
Җиргә буразна сырын.

Буразналар, буразналар –
Йөгерек дулкыннар.
Буразнамда игенкәйләр
Күкрәп уңсыннар!..

# Чайкала иген кырлары

*Галимҗан Латыйп сүзләре, Исмай Шәмсетдинов музыкасы*

Чайкала иген кырлары,
Уяна таң нурлары;
Киңлекләргә алып бара
Безнең басу юллары.

Игенченең уңганлыгы,
Игенченең хезмәт яме,
Игенченең тырышлыгы
Кырларыннан күренә.

Бер офыктан бер офыкка
Җәелгән иген кыры.
Иртәдән кичләргә кадәр
Яңгырый хезмәт җыры.

Игенченең уңганлыгы,
Игенченең хезмәт яме,
Игенченең тырышлыгы
Кырларыннан күренә.

Без барасы юллар якты,
Безнең юллар үр менә.
Бу кырларда җигүле ат
Дугасыннан күмелә.

Игенченең уңганлыгы,
Игенченең хезмәт яме,
Игенченең тырышлыгы
Кырларыннан күренә.

# Арышлар

*Фаил Шәфигуллин сүзләре, Сәлимә Шәмсина музыкасы*

Оныта алмыйм һаман,
Газапланам, янам,
Инде кайда гына йөрмәдем.
Күңелемдә арыш –
Сары сагыш.
Башак шавын ишетәм төннәрен,

Узса җилләр исеп,
Дулкынлана ничек,
Офыкларга җитеп офыктан.
Күпме җырлар оттым
Һәм онытттым,
Тик арышлар җырын онытмам,

Дулкынлана арыш,
Басуларда сагыш,
Көннәр инде көзгә авышкан.
Авылым кырларына
Мин һаман да
Сезне сагынып кайтам, арышлар.

# Балкый Шәйморза утлары

*Мостафа Ногман сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Балкый Шәйморза утлары
Зәңгәр таңнарга кадәр.
Шәйморзаны оныта алмыйсың,
Бер барып күрсәң әгәр.

Шәйморза, Шәйморза,
Туган җиребез Шәйморза;
Безнең яшьлек елларыбыз
Гөр килеп синдә уза.

Макталмый безнең Шәйморза
Урманнар, күлләр белән.
Балкый ул кайнар йөрәкләр,
Якты күңелләр белән.

Шәйморза, Шәйморза,
Туган җиребез Шәйморза;
Безнең яшьлек елларыбыз
Гөр килеп синдә уза.

Яшь кызларын, егетләрен
Шәһәрләр, вузлар тарта.
Бик күпләре канатланып
Туган якларга кайта.

Шәйморза, Шәйморза,
Туган җиребез Шәйморза;
Безнең яшьлек елларыбыз
Гөр килеп синдә уза.

Яңара безнең Шәйморза,
Нурланып үсә һаман,
Илебез күгендә янган
Якты бер йолдыз сыман.

Шәйморза, Шәйморза,
Туган җиребез Шәйморза;
Безнең яшьлек елларыбыз
Гөр килеп синдә уза.

# Чистай вальсы

*Фәтхерахман Әхмәдиев сүзләре һәм музыкасы*

Гүзәл Кама буйларында
Урман, күлләр, болыннар.
Кичке нурлар яктысында
Уйный серле дулкыннар.
Чистай вальсына
Ашкына хисләр.
Җыр белән уза
Чистайда кичләр.

Гөрли Кама, җырлый Кама, –
Ярда Чистай каласы.
Чистай үсә, җырга күчә
Шат, бәхетле авазы.
Яшәү шатлыгы
Чистай җырында,
Чистай сәгате
Дуслар кулында.

Агыйделнең суын алып,
Кама коя Иделгә;
Шат күңелле халкы белән
Чистай яши күңелдә.
Омтыла хисләр
Чистай ягына –
Якын дусларны
Күңел сагына.

# Ямьле безнең Минзәләбез

*Эльмира Шәрифуллина сүзләре, Әнвәр Бакиров музыкасы*

Сандугач сайрый тирәктә,
Сайрый Ык буйларында.
Уңган кызлары мактала
Халкыбыз җырларында.

Ямьле безнең Минзәләбез,
Муллык арта кырларында.
Хезмәттән соң яшьләр күңел ача
Урманында, тугайларында.

Диңгез кебек дулкынлана
Киң басуларда иген.
Кара алтын бүләк итә
Эшчән егетләр бүген.

Ямьле безнең Минзәләбез,
Муллык арта кырларында.
Хезмәттән соң яшьләр күңел ача
Урманында, тугайларында.

Илебездә дан казанды
Минзәлә алмалары.
Кая барсаң да күңелдә
Сызылып аткан таңнары.

Ямьле безнең Минзәләбез,
Муллык арта кырларында.
Хезмәттән соң яшьләр күңел ача
Урманында, тугайларында.

# Күрәсем килгән иде

*Шәмсия Җиһангирова сүзләре, Ганс Сәйфуллин музыкасы*

Минем сине, минем сине
Күрәсем килгән иде.
«Хәлең ничек, хәлең ничек?» –
Диясем килгән иде.
Күзләреңне, күзләреңне
Үбәсем килгән иде.
«Онытмадым, онытмадым», –
Диясем килгән иде.

Минем сине, минем сине
Күрәсем килгән иде.
Сөймәгәнеңне белсәм дә,
Сөясем килгән иде.
Күзләреңне, күзләреңне
Үбәсем килгән иде.
«Мин дә моңлы, син дә моңлы», –
Диясем килгән иде.

Минем сине, минем сине
Күрәсем килгән иде.
«Ярат мине, ярат мине»,–
Диясем килгән иде.
Күзләреңне, күзләреңне
Үбәсем килгән иде.
«Миндә – син бар, синдә – мин бар», –
Диясем килгән иде.
Күзләреңне, күзләреңне
Үбәсем килгән иде.
«Онытмадым, онытмадым», –
Диясем килгән иде.
Күрәсем килгән иде...

# Эзләдем, бәгырем, сине

*Әхмәт Ерикәй сүзләре, Сәйяр Хәбибуллин музыкасы*

Кәккүк кычкыра сирәк кенә,
Сагынуын сөйләп кенә.
Килсәң иде, иркәм, яныма
Көлемсерәп кенә.

Эзләдем, бәгырем, сине,
Еллар буе тилмереп;
Туймас, ахры, мәңге туймас
Күзләрем сине күреп.

Зәңгәр елгалар чылтырап ага,
Нур сибә кояш көлеп;
Алмагачлар ак шәлен ябынган,
Иркәм, синең кебек.

Эзләдем, бәгырем, сине,
Еллар буе тилмереп;
Туймас, ахры, мәңге туймас
Күзләрем сине күреп.

Минем юлыма нурлар
Алып кил күбрәк итеп;
Алсу гөлләр өзеп бирермен
Сиңа бүләк итеп.

Эзләдем, бәгырем, сине,
Еллар буе тилмереп;
Туймас, ахры, мәңге туймас
Күзләрем сине күреп.

# Әгәр белгән булсам

*Шәриф Биккол сүзләре, Әнвәр Бакиров музыкасы*

Кайгылар да баса алмас иде
Йөрәгемдә ташкан шатлыкны,
Әгәр белгән булсам,
Әгәр белгән булсам
Бу дөньяда синең барлыкны...

Алларыңа чыгып торыр идем,
Тик син булыр идең көткәнем,
Әгәр белгән булсам,
Әгәр белгән булсам
Сукмагыңның кайдан үткәнен...

Һичкемгә дә бүләк итмәс идем
Яшьлегемнең тәүге таңнарын,
Әгәр белгән булсам,
Әгәр белгән булсам
Сине очратачак таң барын...

# Мин килермен каршыңа

*Шамил Рәкыйпов сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы*

Болыннарда йөрим сине уйлап,
Болыннарда сагыш онтыла.
Сайрый тургай, моңланмаска куша,
Күңел сиңа гына омтыла.

Чәчәк җыеп, чәчәк тотып,
Мин килермен каршыңа.
Хыялыңда йөрегән мин ул,
Бердәнбер тиң яр сиңа.

Сиңа гына бүләк итәр идем,
Тәүге чәчәкләрнең барсын да.
Тәүге чәчәкләрдән дә назлырак
Керсез мәхәббәтем бар сиңа.

Чәчәк җыеп, чәчәк тотып,
Мин килермен каршыңа.
Хыялыңда йөрегән мин ул,
Бердәнбер тиң яр сиңа.

# Күңелле ял итегез

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин музыкасы*

Ал шәфәкъта, алтын сыман
Кызарып, кояш бата.
Йолдызларга көлемсерәп,
Зәңгәр күктә ай калка.
Эштә үткәндер көнегез,
Ямьле булсын кичегез.
Ай сокланып йөрсен күктә,
Күңелле ял итегез.
Йөрәкләрне җилкендереп,
Яңгырый гармун чыңы.
Әйдә, дустым, вальс биик,
Ардырмыйк гармунчыны.
Очып әйләнәсе килә,
Яшьлекне канат итеп.
Таңны каршылыйсы килә,
Йолдызга барып җитеп!

# Пар алма

*Сания Әхмәтҗанова сүзләре, Зөфәр Хәйретдин музыкасы*

Алларыма килеп тезләндең син,
Кулларыңда иде пар алма.
Төшләремә кереп һәркөн шулай
Таң атуга китеп югалма.

Өзелеп лә төште пар алмакай,
Ятимләнеп калды алмагач.
Өзелә бит инде үзәккәем,
Ялгызлыктан дәва булмагач.

Пар алмадай, пар алмадай идек –
Үз күзләрем тиде, күрәсең.
Пар алмадай бигрәк татлы булып,
Төшләремә минем керәсең.

Өзелеп лә төште пар алмакай,
Ятимләнеп калды алмагач.
Өзелә бит инде үзәккәем,
Ялгызлыктан дәва булмагач.

Җаңга ява бары салкын көзләр,
Бар төсләрне җиргә тигезләп.
Төшләремә кергән пар алманы
Бакчаларда йөрим мин эзләп.

Өзелеп лә төште пар алмакай,
Ятимләнеп калды алмагач.
Өзелә бит инде үзәккәем,
Ялгызлыктан дәва булмагач.

Өзелә бит инде үзәккәем,
Ялгызлыктан дәва булмагач.
Ялгызлыктан дәва булмагач.
Ялгызлыктан дәва булмагач.

# Җырлыйм әнием турында

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре*
*Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы*

Бер кыз бала җыр чыгарган,
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк, диеп,
Өйрәткән энесенә:

*«Кояш, кояш мәңге балкый,*
*Мәңге нур сибә;*
*Кояш гомере телим мин,*
*Әнием, сиңа!»*

Җырны чишмәләр ишеткән,
Кошлар отып алганнар.
Сандугачлар һәм тургайлар
Матур көйгә салганнар:

*«Кояш, кояш мәңге балкый,*
*Мәңге нур сибә;*
*Кояш гомере телим мин,*
*Әнием, сиңа!»*

Кушыл син дә, җырлыйк бергә,
Яңа матур җыр тусын.
Җирдә әниләр, кояштай,
Озын гомерле булсын:

*«Кояш, кояш мәңге балкый,*
*Мәңге нур сибә;*
*Кояш гомере телим мин.*
*Әнием, сиңа!»*

# Әниемә

*Гафур Каербеков сүзләре, Шәмши Калдаяков музыкасы*
*Госман Әхмәтҗанов тәрҗемәсе*

Биргәнсең син миңа ал нурын таңнарның,
Җыйгансың син миңа бар гөлен даланың,
Биргәнсең канатлар талпыныр чагымда,
Балалык рәхмәтем җырымда чагыла.

Кушымта:
Кадерләп үстергән мин синең җимешең.
Куеның – гөлбакча, назлы җил – сулышың,
Инде буй җитсәм дә, мин сиңа сабыймын,
Күңелең назларын күзеңнән таныймын.

Боларга бәрабәр ни генә бирәем,
Бердәнбер бүләгем – тугры йөрәгем.
Итә күр канәгать, риза бул шушыңа,
Үзеңә аталган җырымны кушып ал.
Кушымта.

Бурычлы сиңа мин, әнкәем – алтыным,
Сиңа дип эзләдем дөньяның асылын,
Ай белән кояшны бирим дип уйладым.
Үрелеп алырга җитмәде буйларым.
Кушымта.

# Гөлләр иле

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Сәлимә Шәмсина музыкасы*

Туган ягым – гөлләр иле,
Гөлләр, сөмбелләр иле.
Гөлгә кунып сайрап кына
Үскән былбыллар иле.

Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.

Туган ягым – гөлләр иле,
Гөлгә тиң таллар иле.
Ефәк кебек сызылып кына
Аткан ал таңнар иле.

Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.

Туган ягым – гөлләр иле,
Борынгы Болгар иле.
Бүген көрәштә, хезмәттә
Җиңгән батырлар иле.

Гөлдән гөлгә серем сөйләп,
Болыннарны буйладым.
Туган якның гүзәллеген
Мәңге күреп туймамын.

# Иркәң буласым килә

*Лена Шагыйрьҗан сүзләре, Фасил Әхмәтов музыкасы*

Иркәң буласым килә,
Бикәң буласым килә.
Җилләреңә буйсынырлык
Җилкән буласым килә.

Йә колың булыр идем,
Уң кулың булыр идем.
Сагышлы, моңлы сазыңның
Бер кылы булыр идем...

Иркәм, дип дәшүләрең,
Бикәм, дип дәшүләрең.
Тутырып-тутырып карамадың,
Әллә читләшүләрең?!

Йә көнең булыр идем,
Ак төнең булыр идем.
Туфрагыңда чәчәк аткан
Бер гөлең булыр идем...

# Яшьлек эзләре

*Мансур Шиһапов сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Җил белән серләшкән каеннар
Яңарта яшьлегем хисләрен.
Шомыртлар ак шәлен ябынгач
Сагынам авылым кичләрен.
Сагынам, өзелеп сагынам,
Ялкынлы яшьлекнең эзләрен.

Назлы җил, йомшак җил китерә
Чәчәкле болынның исләрен.
Мин тоям шул җылы җилләрнең
Яшьлектән наз булып искәнен.
Сагынам, өзелеп сагынам
Ялкынлы яшьлегем эзләрен.

Чишмәләр җырлыйлар моң итеп,
Җырлыйлар яшьлегем хисләрен.
Бирелеп уйларга, хыялга,
Тыңлыйм мин агышын чишмәнең,
Сагынам, өзелеп сагынам
Ялкынлы яшьлегем эзләрен.

# Мине юллар чакыра

*Нажар Нәҗми сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы*

Мине юллар, юллар чакыра...
Чакырган юл якын дус кебек;
Мине якын дусым чакыра икән –
Ерак аралар җирдә юк кебек,
Чакырган юл якын дус кебек.

Мине юллар, юллар чакыра...
Китәсең, дип авыр сулама.
Йөрәк сагышлары, тугры дус кебек,
Еллар һәм юллар аша сынала,
Китәсең, дип авыр сулама.

Мине юллар, юллар чакыра...
Юлдагылар юлда булсыннар,
Тугры дуслар кебек шушы минутлар
Безне сагынып көтеп торсыннар,
Юлдагылар юлда булсыннар!

# Юкка үпкәләмә

*Вәлит Илембәтов сүзләре, Венер Мөхәммәдиев музыкасы*

Күңелкәем канатланды
Сине тәү күргән чакта;
Хәзер яна йөрәккәем
Уйласам синең хакта.

Юкка үпкәләгән булып,
Ятларга китәсең бит;
Аны, мине, үзеңне дә
Бәхетсез итәсең бит.

Онып, дисең, араларны
Ничек өзәем икән;
Аерылу газабына
Ничек түзәем икән?

Юкка үпкәләгән булып,
Ятларга китәсең бит;
Аны, мине, үзеңне дә
Бәхетсез итәсең бит.

Хәтерләсәң яшьлегеңне,
Күзләреңә яшь тулыр;
Эх, диеп бер үкенерсең –
Гомерләр үткән булыр...

Юкка үпкәләгән булып,
Ятларга китәсең бит;
Аны, мине, үзеңне дә
Бәхетсез итәсең бит.

# Әле дә син бар әле дөньяда

*Шәриф Биккол сүзләре, Байрас Абдуллин музыкасы*

Күптән инде әйтер хисләрем бар
Кем яулавын күңел түремне.
Айга бары ачам йөрәгемне,
Ай тапшырсын сиңа серемне.

Күзләремә бер каравың җитә
Бөтен кайгыларым югала.
Әле дә син бар әле бәхетемә,
Әле дә син бар әле дөньяда.

Тәрәз шакып назлы таң җилләре
Миннән сиңа сәлам китерер.
Тыңла күңел биреп, алар сиңа
Минем сүзләремне җиткерер.

Күзләремә бер каравың җитә
Бөтен кайгыларым югала
Әле дә син бар әле бәхетемә,
Әле дә син бар әле дөньяда.

# Эх, сез матур кызлар

*Николай Васильев сүзләре, Петр Кубашев музыкасы*
*Удмуртчадан Риф Насыйбуллин тәрҗемәсе*

Дус-ишләрем уйный-көлә,
Мин генә көлмим.
Уенның да ямен тапмыйм,
Ни булды, белмим.
Эх, сез матур кызлар,
Ник шаяртасыз?
Йөрәгемнең януларын аңламыйсыз.

Мин эшемдә гел почетта,
Һәрчак мактыйлар.
Кызлар гына урап уза,
Эх, яратмыйлар.
Эх, сез матур кызлар,
Ник шаяртасыз?
Йөрәгемнең януларын аңламыйсыз.

Йөрәгемдә утлар яна,
Һич төшенмисез.
Арагыздан берегезне
Сөям өметсез.
Эх, сез матур кызлар,
Ник шаяртасыз?
Йөрәгемнең януларын аңламыйсыз.

Нигә сезгә аңлашылмый
Минем хисләрем.
Шулай ук ялгыз үтәрме
Минем кичләрем?
Эх, сез матур кызлар,
Ник шаяртасыз?
Йөрәгемнең януларын аңламыйсыз.

# Яшь күңел

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Син яшь, диләр, һәрвакыт яшь күңелле, диләр,
Көннән-көн яшәрәсең, дип, миннән көнлиләр;
Яшәрәм, дусларым, чөнки гүзәл яшьлеккә гашыйк мин,
Шуңа күрә картаерга бер дә ашыкмыйм.

Син шат, диләр, һәрвакыт шат күңелле, диләр,
Шат күңелле булуыңның серен әйт, диләр.
Күңелем шат, чөнки, дуслар, яшим мин бәхет илендә,
Чәчәк аткан гөлбакчадай туган җиремдә.

Син бик уңган, карлыгачтай бик җитез, диләр,
Колхоз кырларында эшләп үстеңме, диләр.
Эшләп үстем, дусларым, мин тургайларның җырын тыңлап,
Шуңа күрә тургай сыман яшим мин җырлап.

# Йөрәк сере

*Илсөяр Ганиева сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы*

Давылларда очты ал яулыгым,
Бәлки, табалырсың ишкәен.
Яшьли сөйгән ярым ятка калды,
Әйтегезче, дуслар, нишләем?

Аның йөрәге дә юксынудан
Сызланадыр кебек гомергә.
Ара ераклаша, тик нигәдер
Кавышырбыз кебек күңелгә.

Ник моң булып кердең тормышыма,
Нур сипмәгәч таңнар аткандай?
Әмма сүнмәс рухым һаман көчле,
Дәрья суы ташып аккандай.

# Агыйдел каты ага

*Татар халык җыры*

Агыйделдә йөзсәң иде
Камыштан көймә үреп;
Былбыл булып, гөлгә кунып
Сөйләшсәң иде күреп.

Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә;
Сөясеңме, сөймисеңме –
Шуны беләсем килә.

Аклы күлмәкнең җиңе тар,
Җиң очында хаты бар;
Хатын укып карагачтын
Сөям дигән сүзе бар.

Агыйдел күпере,
Чуенмы әллә чылтырый;
Каш астында ике күзе
Энҗе кебек елтырый.

Агыйделдән көймә килә
Кылдан нечкә эз белән;
Җаным, нигә хәтерең калды
Уйнап әйткән сүз белән?!

Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә;
Сөя микән, сөйми микән –
Шуны беләсем килә.

# Гармун моңнары

*Сәрия Мәһдиева сүзләре, Әбүзәр Солтанов музыкасы*

Күңелләрне тибрәндерә
Гармун моңнары:
Хәтерләтә үткәннәрне
Яшьлек елларын.
Күз алдымда сине сагынып
Көтеп алганым,
Синең белән каршылаган
Алсу таңнарым.

Тәүге сөю хисләремне
Онытырлык түгел,
Өмет белән көтте һаман
Тынгысыз күңел.
Кайталмадың, калды бары
Таныш моңнарың.
Ялгызлыкта үтте инде
Гомер елларым.

Күңелләрне тибрәндерә
Гармун моңнары.
Хәтерләтә үткәннәрне,
Яшьлек елларын.
Гармуныңны дустың уйный,
Әйдә, уйнасын.
Тик сөйгәне минем кебек
Ялгыз булмасын.

# Аллы-гөлле гөлчәчәк

*Татар халык җыры*

Аллы-гөлле гөлчәчәкне
Иснә, бәгырем, исле ул;
Үзе алсу, үзе нәфис,
Бигрәк синең төсле ул.

Гөл чәчәгенә бәйләнеп,
Чия пешә бал кебек.
Буең зифа яшь тал кебек,
Йөзең тулган ай кебек.

Алларым, диям сине,
Гөлләрем, диям сине;
Аллы-гөлле чәчәгем, дип
Өзелеп сөям сине.

Гөл чәчәгенә бәйләнеп,
Чия пешә бал кебек.
Буең зифа яшь тал кебек,
Йөзең тулган ай кебек.

# Хәерле юл

*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Шәүкәт Капкаев музыкасы*

Иртә таңда китсәң бер юл сайлап,
Юлдаш булсын сиңа кошлар сайрап.
Юлларың уңсын,
Күңелле булсын,
Кайт шул ук юл буйлап.

Озын юллар кыска тоелыр,
Матур җырлар җырлап йөрсәң,
Ак чәчәкләр белән каршы алырмын,
Сагынып кайтып керсәң.

Җил-давыллар каршы искән чакта,
Борылып кара туган-үскән якка.
Ә туган ягың
Һәм сөйгән ярың
Уйлар синең хакта.

Озын юллар кыска тоелыр,
Матур җырлар җырлап йөрсәң,
Ак чәчәкләр белән каршы алырмын,
Сагынып кайтып керсәң.

Кайгың булса, юлда кайгың бетсен,
Чакрым саен сине бәхет көтсен,
Иртәнге җилләр,
Чәчәкләр, гөлләр
Битләреңнән үпсен!..

Озын юллар кыска тоелыр,
Матур җырлар җырлап йөрсәң,
Ак чәчәкләр белән каршы алырмын,
Сагынып кайтып керсәң.

# Җәйнең матур аяз таңнарында

*Әхмәт Ерикәй сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы*

Җәйнең матур аяз таңнарында
Җанга рәхәт Идел ярларында;
Чык җемелдә миләш яфрагында,
Елмаялар гөлләр болында.

Кошлар сайрый яшел куакларда
Яшәү матурлыгы турында.

Минем хәлләремне, минем хисне
Идел дулкыннары сөйли төсле;
Алкын Идел үзе тели төсле
Минем белән сердәш булырга.

Кошлар сайрый яшел куакларда
Яшәү матурлыгы турында.

Хәтерләтеп дулкын уйнауларын,
Уйный минем якты хыялларым;
Мәхәббәтем, дәртем, идеалларым
Күпер булыр барыр юлымда.

Кошлар сайрый яшел куакларда
Яшәү матурлыгы турында.

# Уф, йөрәгем

*Татар халык җыры*

Җиделе лампа, бишле куык
Ватылды, җиргә төште, шул;
Уф, йөрәгем, су бирегез,
Иркәм исемә төште.

Яңа өемнең түрләренә
Элеп куйдым тастымал, шул;
Уф, йөрәгем, су сибегез,
Ут кабуы ихтимал.

Иртә торып тышка чыксам,
Фонтаннардан су алам, шул;
Уф, йөрәгем, сүндерегез,
Синең утларда янам.

Урман буйларында йөргән
Чакларны сагынырсың, шул;
Уф, йөрәгем, килмә якын,
Утына кабынырсың.

# Солдатлар

*Роберт Әхмәтҗанов сүзләре*
*Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы*

Озатып вокзаллар каршында
Маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
Дөньяны күрмәгән балалар.

Балалар керделәр утларга,
Балалар сүз бирде тупларга.
Күпләре, төренеп шинельгә,
Калдылар еракта йокларга.

«Балалар, торыгыз, балалар,
Ашыгыз суына табында...»
Ничә ел тормыйлар балалар
Иделдә һәм Дунай ярында...

Уятма, йокласын, син, ана,
Айларны, елларны санап бар:
Күңелдә һаман яшь, гел бала –
Кайтмаган солдатлар, солдатлар.

Ана ул йокламый, сабые
Юрганын ачса да уяна.
Аналар йөрәге шикелле
Мәйданда мәңгелек ут яна.

Аналар йөрәге шикелле
Ут яна, уйлана, талпына.
Аналар хәтере шикелле
Җил йөри курганнар артында.

# Идел буе каеннары

*Әхмәт Ерикәй сүзләре, Илһам Шакиров музыкасы*

Күпме карасам да, карап туймыйм
Идел буе каеннарына.
Алар, җитәкләшеп, яланаяк
Чыгар төсле Идел ярына.

Мин яратам сезне, кардәшләрне,
Хөрмәт иткән кебек яратам;
Шуңа күрә сезгә багышланган
Йөрәк җырларымны яңартам.

Каеннарның җилдә тирбәлүе
Рәхәт бирә минем күңелгә.
Белмим, күпме туры килер икән
Туган илем буйлап йөрергә…

Баганалы юлдан күз алмыйча,
Моңсуланып тора имәннәр.
Үсмер имәннәрне иркәләргә
Нәзек билле җилләр килгәннәр.

Мин кояшка таба, таңга таба,
Яз түренә таба юл алам;
Гөлләр арасына, үләннәргә,
Үзәннәргә кереп югалам…

Әгәр, сездән аерып, еракларга
Алып китә калса юлларым,
Каен шаулавында ишетермен
Туган җирнең үлмәс җырларын.

*Хөрмәтле тыңлаучыбыз!*

*«АКСУ» студиясе җаныгыз теләгән CD, MP3, DVD-форматындагы музыкаль продукцияләр, татар, урыс телләрендә басылган дини китаплар, җыр китапларын, шагыйрьләребезнең, язучыларыбызның тарих, милләт турында язылган шигырьләрен, романнарын һәм башка әсәрләрен почта аша соратып алырга мөмкин.*

*Рәхим итегез!   «АКСУ» студиясе.*






# ЭЧТӘЛЕК

(алфавит буенча)

1. **Агыйдел каты ага** *Татар халык җыры* 99
2. **Аерылабыз** *Татар халык җыры* 26
3. **Аерылмагыз**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Чулпан Зиннәтулина музыкасы* 64
4. **Ай былбылым** *Татар халык җыры* 28
5. **Ай, җаный, суларда** *Татар халык җыры* 13
6. **Ак кораб** *Татар халык җыры* 23
7. **Ак чәчәкләр** *Әкрам Даутов сүзләре һәм музыкасы* 44
8. **Аллы-гөлле гөлчәчәк**
*Татар халык җыры* 101
9. **Алмагачлары** *Татар халык җыры* 30
10. **Алтын алка** *Татар халык җыры* 45
11. **Арышлар**
*Фаил Шәфигуллин сүзләре, Сәлимә Шәмсина музыкасы* 77
12. **Ашхабад** *Татар халык җыры* 27
13. **Баламишкин** *Татар халык җыры* 4
14. **Балкый Шәйморза утлары**
*Мостафа Ногман сузләре, Сара Садыйкова музыкасы* 78
15. **Белегез шуны**
*Илгизәр Фазлуллин сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы* 48
16. **Беренче мәхәббәт**
*Әхмәт Рәшитов сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы* 8
17. **Буразналар**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Җәүдәт Фәйзи музыкасы* 75
18. **Бәрәңге**
*Мәхмүт Хөсәен сүзләре, Ифрат Хисамов музыкасы* 60

19. **Бөрлегәнем бергенәм** *Татар халы көе* 61

20. **Гармун моңнары**
*Сәрия Мәһдиева сүзләре, Әбүзәр Солтанов музыкасы* 100

21. **Гөлләр иле**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Сәлимә Шәмсина музыкасы* 90

22. **Гөлнарым**
*Гамил Афзал сүзләре, Фәрит Хатыйпов музыкасы* 52

23. **Дусларыңны онытма еллары**
*Әнгам Атнабаев сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы*
*«Яшьлек белән хушлашу» спектакленнән* 72

24. **Замечательная** *Татар халык җыры* 25

25. **Зимфирәкәй**
*Абдулла Мостафин сүзләре, Васил Хәбисламов музыкасы* 51

26. **Зәңгәр төймә** *Татар халык җыры* 6

27. **Идел буе каеннары**
*Әхмәт Ерикәй сүзләре, Илһам Шакиров музыкасы* 106

28. **Иркәң буласым килә**
*Лена Шагыйрьҗан сүзләре, Фасил Әхмәтов музыкасы* 91

29. **Йөрәк сере**
*Илсөяр Ганиева сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы* 98

30. **Казан кичләре**
*Хәсән Туфан сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы* 18

31. **Кайтам инде**
*Илдар Юзеев сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы* 7

32. **Кошлар кебек** *Татар халык җыры* 62

33. **Кыңгыраулы мәктәп еллары**
*Шәүкәт Галиев сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы* 70

34. **Күбәләгем** *Татар халык җыры* 29

35. **Күн авылы көе** *Татар халык җыры* 56

36. **Күрәсем килгән иде**
*Шәмсия Җиһангирова сүзләре, Ганс Сәйфуллин музыкасы* 82

37. **Күңелле ял итегез**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин музыкасы* 86

38. **Мине юллар чакыра**
*Нәҗар Нәҗми сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы* 93

39. **Мин килермен каршыңа**
*Шамил Рәкыйпов сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы* 85

40. **Моңнар кайтсын авылга**
*Рамил Чурагулов сүзләре, Ризван Хәкимов музыкасы* 58

41. **Мәдинәм-гөлкәем** *Татар халык җыры* 9

42. **Мәк чәчәге**
*Альберт Абдуллин сүзләре, Марс Макаров музыкасы* 35

43. **Мәтрүшкәләр**
*Илдар Юзеев сүзләре, Алмаз Гыйлаҗев музыкасы* 40

44. **Назлы гөлкәем**
*Ярлы Кәрим сүзләре, Фасил Әхмәтов музыкасы* 24

45. **Наласа** *Татар халык җыры* 19

46. **Олы юлның тузаны** *Татар халык җыры* 5

47. **Оныттың бугай**
*Гәрәй Рәхим сүзләре, Гали Ильясов музыкасы* 38

48. **Очрашу җыры**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Илһам Шакиров музыкасы* 32

49. **Пар алма**
*Сания Әхмәтҗанова сүзләре, Зөфәр Хәйретдин музыкасы* 87

50. **Рәзинәкәй**
*Салават Сәрвәров сүзләре һәм музыкасы* 53

51. **Сагыну** *Татар халык җыры* 22

52. **Сагыну җыры**
*Гыйльман Идрисов сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы* 21

53. **Сагыш**
*Равил Фәйзуллин сүзләре, Җәүдәт Фәйзи музыкасы* 34

54. **Сарман** *Татар халык җыры* 39

55. **Саубуллашу вальсы**
*Саҗидә Сөләйманова сүзләре, Мәсгут Имашев музыкасы* 47

56. **Сине уйлап янам**
*Илдар Юзеев сүзләре, Сафьян Ибраһимов музыкасы* 41

57. **Сиңа килдем, иркәм**
*Гыйльман Идрисов сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы* 65

58. **Солдатлар**
*Роберт Әхмәтҗанов сүзләре,*
*Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы* 105

59. **Соңлама, кил инде**
*Рәгыйдә Янбулатова сүзләре, Бәхти Гайсин музыкасы* 16

60. **Сәяхәтче җыры**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин музыкасы* 33

61. **Телефоннар** *Рим Хәсәнов сүзләре һәм музыкасы* 68

62. **Туган авылым**
*Нәҗип Иделбай сүзләре, Тәлгать Шәрипов музыкасы* 49

63. **Туган авылым урамы**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Ганс Сәйфуллин музыкасы* 74

64. **Туган авылым**
*Мостафа Ногман сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы* 57

65. **Уф, йөрәгем** *Татар халык җыры* 104

66. **Уфа юкәләре**
*Нажар Нәҗми сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы* 67

67. **Утыр әле яннарыма**
*Шәүкәт Галиев сүзләре, Ифрат Хисамов музыкасы* 12

68. **Хәерле юл**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Шәүкәт Капкаев музыкасы* 102

69. **Чайкала иген кырлары**
*Галимҗан Латыйп сүзләре, Исмай Шәмсетдинов музыкасы* 76

70. **Чистай вальсы**
*Фәтхерахман Әхмәдиев сүзләре һәм музыкасы* 80

71. **Чыгарсыңмы каршы алырга**
*Дамир Гарифуллин сүзләре, Вәсим Әхмәтшин музыкасы* 20

72. **Чәчәкләр уяныр**
*Ринат Мөслимов сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы* 66

73. **Чәчкәләрнең нигә кирәге бар?**
*Нәсимә Абзалова сүзләре, Илһам Хисмәтуллин музыкасы* 63

74. **Эзләдем, бәгырем, сине**
*Әхмәт Ерикәй сүзләре, Сәйяр Хәбибуллин музыкасы* 83

75. **Эх, сез матур кызлар**
*Николай Васильев сүзләре, Петр Кубашев музыкасы*
*Удмуртчадан Риф Насыйбуллин тәрҗемәсе* 96

76. **Юкка түгел, юкка түгелдер**
*Нажар Нәҗми сүзләре, Рим Хәсәнов музыкасы* 69

77. **Юкка үпкәләмә**
*Вәлит Илембәтов сүзләре, Венер Мөхәммәдиев музыкасы* 94

78. **Юллар** *Әхмәт Ерикәй сүзләре, Ләбиб Айтуганов музыкасы* 46

79. **Ядкарь** *Разил Вәлиев сүзләре, Фасил Әхмәтов музыкасы* 37

80. **Ямьле безнең Минзәләбез**
*Эльмира Шәрифуллина сүзләре, Әнвәр Бакиров музыкасы* 81

81. **Яран гөл**
*Резеда Вәлиева сүзләре, Сәүбән Чуганаев музыкасы* 73

82. **Яшь гомер**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин музыкасы* 15

83. **Яшь күңел**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы* 97

84. **Яшьлегем тугае**
*Фаил Шәфигуллин сүзләре, Зиннур Гыйбадуллин музыкасы* 14

85. **Яшьлек эзләре**
*Мансур Шиһапов сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы* 92

86. **Әгәр белгән булсам**
*Шәриф Биккол сүзләре, Әнвәр Бакиров музыкасы* 84

87. **Әйдә, әйдә, кая, кая** *Керәшен халык җыры* 50

88. **Әйткән идең**
*Хәсән Туфан сүзләре, Әнвәр Бакиров музыкасы* 36

89. **Әйтмә син авыр сүз**
*Рамил Чурагулов сүзләре, Ризван Хәкимов музыкасы* 59

90. **Әкълимә** *Рим Хәсәнов сүзләре һәм музыкасы* 54

91. **Әле дә син бар әле дөньяда**
*Шәриф Биккол сүзләре, Байрас Абдуллин музыкасы* 95

92. **Әниемә**
*Гафур Каербеков сүзләре, Шәмши Калдаяков музыкасы*
*Госман Әхмәтҗанов тәрҗемәсе* 89

93. **Өнсә авылы көе** *Татар халык музыкасы* 55

94. **Җаныем, бәгърем** *Татар халык җыры* 17

95. **Җаным җәл түгел сиңа** *Татар халык җыры* 10

96. **Җидегән чишмә**
*Гомәр Бәширов сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы* 42

97. **Җиз кыңгырау моңнары**
*Әнгам Атнабаев сүзләре, Вәсил Хәбисламов музыкасы* 43

98. **Җомга** *Татар халык җыры* 11

99. **Җырлыйм әнием турында**
*Гөлшат Зәйнашева сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы* 88

100. **Җәйнең матур аяз таңнарында**
*Әхмәт Ерикәй сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы* 103


ЯҢА ФОРМАТТА Mp3
Флюра
Сөләйманова


Зөһрә СӘХӘБИЕВА
Мөнәҗәтләр


ХӘЙДӘР БИГИЧЕВ
DVD


Таһир
Якупов
Татар эстрадасы җәүһәрләре
Mp3 Легенды татарской эстрады


Җырлый
Мәсгут
ИМАШЕВ
Mp3



Айдар
Фәйзрахманов
Туган җиреңнән
китмә


Яшик әле
сөенеп
Зөһрә Шәрифуллина


ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МИЛЛИ
МИРАСЫ
Рафаэль
ИЛЬЯСОВ
ҖЫРЛАРЫМДА -
МОҢНАРЫМ
Rafael
ILJYASOV
ТАТАРСТАН ҖЫРЧЫЛАРЫ
Mp3
МУЗЫКАЛЬНЫЙ
ЗОЛОТОЙ ФОНД РЕСПУБЛИКИ


Лена Бичарина


1910-
2010
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ МИРАСЫ
Mp3
Зифа
Басыйрова


DVD
Татарстанның халык артисты
Фердинанд СӘЛАХОВ
Җаным җырда
Душа моя в песнях






















Студия «АКСУ»
Ваши отзывы и пожелания,
а также заказы на CD, MP3, DVD,
книжки-песенники по почте
присылайте по адресу:
ООО «Компания Аксу»
420073 г. Казань, ул. Спортивная, 33
Тел.: 8(843) 20-23-917; 8(843) 246-2-246
89046-746-246
www.aksu-studio.ru сэлам.рф
e-mail: 2959308@mail.ru

Халкыбыз мирасы

**Халкыбызның яраткан җырлары.**
**100 җыр**

1 китап

Төзүчесе Рөстәм Сәрвәров

Наследие нашего народа
Любимые песни народа. 100 песен
1 книга

Корректоры Рүзәл Мөхәмmәтшин
Компьютерда биткә салучысы Борис Садовников
«Халкыбыз мирасы» нәшрияты 2014
Тираж 1 000 данә